| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |
| БОЕРЫК | ПРИКАЗ |
| от 07.07.2014 | № 213 |

**Казан ш.**

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 07.05.2013 ел, №84 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, №210-ФЗ Федераль законга, “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 7 май, 2013 ел, №601 Россия Федерациясе Президенты Указына һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы структурасындагы үзгәрешләргә туры китереп, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 07.05.2013 ел, №84 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген хәл итүгә рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәт дубликатын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3.2.пунктта “Транспорт һәм логистика идарәсенең пассажирлар ташу бүлеге” дигән сүзләрне Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге” дигән сүзләргә алыштырырга;

1.4 пунктта дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 7 май, 2012 ел, №601 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә” (алга таба – №601 Россия Федерациясе Президенты Указы) (РФ законнар җыентыгы, 14.05.2012, №19, 2338 ст.);”;

2.6 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасына түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәргә:

“4.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акча средстволары керү (Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә) турында мәгълүматлар.”;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы. | Чират булганда, кәгазьдә рөхсәт алуга гариза тапшыру – күп дигәндә 15 минут.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категориляәре өчен чират билгеләнмәгән. | №601 Росссия Федерациясе Президенты Указы” |

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.Административ процедуралар составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре,

шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре”;

3.2 пунктта

“икенче абзацта “Транспорт һәм логистика идарәсенең пассажирлар ташу бүлеге (алга таба – Бүлек); дигән сүзләрне “Бүлек” дигән сүзгә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге җиденче абзацны өстәргә:

“Дәүләт хезмәте күп функцияле үзәкләрдә күрсәтелми.”;

3.3.6 пунктта өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акча средстволары керү турында Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә мәгълүматлар тапшыру хакында”;

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Транспорт идарәсе начальнигы А.В.Сидоровка йөкләргә.

Министр Л.Р.Сафин